**Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы**

**БОЕРЫК**

27.09.2013 ел Казан ш. № 02-93

**Финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган, максатчан билгеләнешкә ия булган бюджетара субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар хисабына хәл ителә торган җирле бюджетлар чыгымнарының максатчан статьялары исемлеген һәм кодларын билгеләү тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 21 статьясындагы 4 пункты нигезендә, боерык бирәм:

1.Бу боерыкка кушымта нигезендә, Финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган, максатчан билгеләнешкә ия булган бюджетара субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар хисабына хәл ителә торган җирле бюджетлар чыгымнарының максатчан статьялары исемлеген һәм кодларын билгеләү тәртибен расларга.

2.Бу Боерык нигезләмәләренең, 2014 елга һәм пландагы 2015-2016 еллардагы бюджетлардан башлап, Татарстан Республикасы бюджетын һәм җирле бюджетларны төзегәндә һәм үтәгәндә килеп чыгучы хокукый мөнәсәбәтләргә кагылуын билгеләргә.

3. “Финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган, максатчан билгеләнешкә ия булган бюджетара субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар хисабына хәл ителә торган бюджетлар чыгымнарының максатчан статьялары һәм (яки) төрләре исемлеген һәм кодларын билгеләү тәртибен раслау турында” 29.01.2013 ел, № 02-7 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгын (“Республика Татарстан”, 22 февраль, 2013 ел) 2014 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип танырга.

4. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы финанс министры урынбасарларына йөкләргә.

**Министр Р.Р.Гайзатуллин**

**Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 27.09.2013 ел, № 02-93 боерыгы белән расланды**

**Финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган, максатчан билгеләнешкә ия булган бюджетара субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар хисабына хәл ителә торган җирле бюджетлар чыгымнарының максатчан статьялары исемлеген һәм кодларын билгеләү**

**ТӘРТИБЕ**

1. Бу Тәртип финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган, максатчан билгеләнешкә ия булган бюджетара субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар хисабына хәл ителә торган җирле бюджетлар чыгымнарының максатчан статьялары исемлеген һәм кодларын билгеләү механизмын билгеләи.

2. Финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган, максатчан билгеләнешкә ия булган бюджетара субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар хисабына хәл ителә торган, чираттагы финанс елында һәм планда каралган чорда җирле бюджетлар чыгымнарының максатчан статьялары исемлеге һәм кодлары Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгы белән расланган чыгымнарның максатчан статьялары исемлеге һәм кодлары нигезендә булдырыла.

3. Максатчан билгеләнешкә ия булган бюджетара субсидияләрнең, субвенцияләрнең һәм башка бюджетара трансфертларның һәр төренә максатчан статья коды бирелә. Максатчан статья коды җиде билгедән тора – 20 урынлы чыгымнар классификациясе кодының 8 дән алып 14 нче разрядына кадәр.

4. Җирле үзидарә органнары тарафыннан, җирле бюджетларны раслауда һәм үтәүдә, шулай ук средстволарны муниципаль районнар бюджетларыннан җирлекләр бюджетларына күчерүдә, түбәндәге тәртиптә, максатчан билгеләнешкә ия булган бюджетара субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар бирү өчен Татарстан Республикасы бюджетындагы максатчан статьялар кодларының дәвамчанлыгы тәэмин ителә:

дәүләт программаларына кертелгән Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының максатчан статьялары кодлары буенча чыгымнарның максатчан статьялары кодларының 11-14 разрядлары саклана;

дәүләт программаларына кертелмәгән Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының максатчан статьялары кодлары буенча чыгымнарның максатчан статьялары кодларының 8-14 разрядлары саклана.